| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«УРМЫШЛИНСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ОРМЫШЛЫ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 31 октябре №32

Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге Бохар торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 статьясы нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Урмышлы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск муниципаль районы Урмышлы авыл җирлеге Бохар торак пунктында үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2022 елның 19 ноябренә 13 сәгать 00 минутта дип билгеләргә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Сез 2023 елда үзара салым кертүне Лениногорск муниципаль районының Урмышлы авыл җирлеге Бохар торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән алынган средстволарны җирле әһәмияттәге түбәндәге эшләрне башкаруны хәл итүгә юнәлдерүгә 500 (Биш йөз) сум күләмендә билгеләү белән килешәсезме:

1 Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, предметы җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләре булган төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, инвалидлар өчен социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы һәм күрсәтелә торган хезмәтләр күрсәтү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:

- МТЗ-81.1 тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, тракторчы хезмәтләре өчен түләү).

2. Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

-юлларны кардан чистарту;

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урмышлы авылы, Үзәк урам, 4, Бохар авылы, Чишмәле урамы, 2, Бохар авылы Авангард урамы, 23 адресы буенча урнашкан махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Лениногорск муниципаль районы рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru/) урнаштырырга.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Урмышлы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы А.Ф.Хәбибуллин